| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| Исполнительного комитета Азнакаевского муниципаль районы | | Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты |
| Ленин ур., 22 й., Азнакай ш., 423330<br>Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97<br>E-mail: aznakay@tatar.ru<br>adm-aznakay@mail.ru | | Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330<br>Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97<br>E-mail: aznakay@tatar.ru<br>adm-aznakay@mail.ru |

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**"04" август 2022 ел** **№ 206**

Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 02 апрлендәге 105 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмә»карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (204 елның 03 августындагы 204 номерлы редакциядә)

Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының "Муниципаль берәмлекләрдә һәм оешмаларда гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы Нигезләмәне раслау турында" 2008 елның 14 нче 11 нче декабрендәге 687 нче боерыгын үтәү йөзеннән һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында гражданнар оборонасы чараларын һәрьяклап тәэмин итүне оештыру максатларында карар бирә:

1. Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 02 апрлендәге 105 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмә»карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәгә (204 елның 03 августындагы 204 номерлы редакциядә )түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 7 пунктның беренче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«7. Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты карары буенча коткару хезмәтләре (медицина, инженерлык, коммуналь-техник, янгынга каршы, җәмәгать тәртибен саклау, үсемлекләрне һәм хайваннарны яклау, элемтә һәм хәбәр итү, ягулык-майлау материаллары, юл, энергетика, сәүдә һәм туклану, санитар-эпидемиологик күзәтчелекне) төзелергә мөмкин, аларның эшчәнлеген оештыру һәм тәртипләре коткару хезмәтләре турындагы тиешле

нигезләмәләрдә аларны булдыручы органнар һәм оешмалар тарафыннан билгеләнә.”;

1.2 пунктчасының икенче абзацын төшереп калдырырга;

1.3. дүртенче абзацта «формированиеләр һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.4. 13.1 пунктчасының җиденче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«гражданнар оборонасы курсларын һәм гражданнар оборонасы буенча укыту-консультация пунктларын булдыру, җиһазландыру һәм аларның эшчәнлеген оештыру йә халыкның тиешле төркемнәрен укыту курсларын тәэмин итү һәм халыкка башка оешмаларда гражданнар оборонасы өлкәсендә консультация хезмәтләре күрсәтү;».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А. Х. Шәмсетдинов